СИШӘМБЕ
16
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 38 (6760)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

ЧӘЧҮ ОРЛЫКЛАРЫН ӘЗЕРЛӘҮНЕ АШЫКТЫРЫРГА

Үткән елны, республикабызның кайбер колхозларында, чәчү орлыкларын салуга, аларны әшкәртүгә вакытында керешмәү һәм бигрәк тә орлыкларны саклауга тиешенчә әһәмият бирмәү нәтиҗәсендә, начар сыйфатлы орлык чәчтеләр. Билгеле, начар сыйфатлы орлыктан яхшы уңыш көтеп булмый.

Үткән елгы бу җитди кимчелекне күп кенә колхозларыбыз быел, табигый, бик нык искә алып, чәчү орлыкларын әзерләүгә көздән үк керештеләр, һәм алар инде үзләрен барлык культуралар буенча да чәчү орлыклары белән тулысынча тәэмин иттеләр.

Бу өлкәдә яхшы эшләүчеләр сыйфатында һәм күпләргә үрнәк итеп Апас районының «Яңа ил» һәм Энгельс исемендәге колхозларын, Әлмәт районының «Морат», «Элькомс» һәм «Кызыларменец» колхозларын, Биектау районының «Урал» һәм «Искра» колхозларын алырга мөмкин. Мондый колхозларыбыз башка районнарда да, билгеле, күп. Аларда барлык орлыклар да җитәрлек күләмдә салынган һәм тазартылган. Орлыклар коры урыннарда саклаанлар, аларның тишелеп чыгу дәрәҗәләре әледән-әле тикшерелеп торыла.

Кыскасы, бу колхозлар чәчү орлыклары әзерләү буенча чын-чыннан хуҗаларча кайгыртучанлык күрсәтәләр. Һәрбер колхозда һәм совхозда шулай булырга тиеш. Чөнки яхшы сыйфатлы орлык ул,—югары игеп уңышының төп шарты.

Ләкин язгы чәчүгә уңышлы әзерлекнең хәлиткеч бу тармагына җитәрлек әһәмия бирмәүчеләр, кызганычка каршы, быел да бар. Мәсәлән, Мамадыш районының күп кенә колхозларында хәл әнә шундый. Бу районның кайбер колхозларында орлыкка дигән ашлыклар хәтта сугылмаган да әле. Ни өчен? Чөнки Мамадыш районы җитәкчеләре, шулай ук район җир бүлеге һәм МТС работниклары чәчү орлыкларын әзерләүгә һаман да әле икенче чираттагы эш итеп карыйлар. Бу районда күп кенә орлык чистарту машиналары һәм МТС ның бөтен-бөтен агрегатлары хәзерге көндә дә әле файдаланылмыйча тик яткырылалар. Күп кенә колхозларда орлыкларның тишелеп чыгу дәрәҗәләре бер генә тапкыр да тикшерелгәне юк. Район орлык лабораториясе эшлексезлек күрсәтә, тикшерү өчен колхозлардан орлыкның китерелүен көтеп ята, бу эшне оештыруда инициатива күрсәтми.

Кызыл Армия, Яңа Чишмә, Ворошилов, Биләр һәм башка кайбер районнарда да чәчү орлыкларын әзерләү һич тә гафу ителмәслек дәрәҗәдә акрын бара.

Яз җитә. Язгы чәчүгә барлык тармаклар буенча да әзерлекне көчәйтү белән беррәттән орлык мәсьәләсенә аеруча җитди игътибар бирелергә тиеш. Орлыклык участоклардан җыелган ашлыкларны тизрәк сугарга һәм кичекмәстән әшкәртү эшенә керешергә кирәк. Кышка кергәч сугылып салынган орлыкларның саклаанышын аерым күзәтү астына алырга, бу эш белән турыдан-туры колхоз җитәкчеләре үзләре шөгыльләнергә тиешләр.

Кайбер колхоз җитәкчеләре, чәчү орлыклары мәсьәләсендә һаман да әле дәүләт амбарларына исәп тоталар. Бу—бөтенләй ялгыш фикер! Дәүләткә ашлык тапшыру планын тизрәк һәм һич сүзсез үтәү буенча кискен чаралар күрелү белән беррәттән, һәрбер колхоз һәм совхоз, ниһаять, һәрбер район чәчү орлыклары белән үзен тулысынча тәэмин итәргә тиеш. Моның өчен урындагы эчке мөмкинлекләрдән файдалануны яхшылап оештырырга, районара һәм колхозара орлык алмашу эшен киң җәелдерергә кирәк.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

I.

КӨНЬЯК ФРОНТ ГАСКӘРЛӘРЕ РАСТОВ-ДОННЫ АЛДЫЛАР

Генерал-полковник иптәш Р. Я. МАЛИНОВСКИЙ командалыгындагы Көньяк фронт гаскәрләре берничә көн буена РОСТОВ-ДОН шәһәре өчен бик каты сугышлар алып бардылар. Бүген, 14 нче февральдә, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, безнең гаскәрләр РОСТОВ-ДОН шәһәрен алдылар.

РОСТОВ өчен булган сугышларда генерал-лейтенант иптәш В. Ф. ГЕРАСИМЕНКО гаскәрләре үзләрен аеруча күрсәттеләр. Шәһәргә беренче булып подполковник иптәш КОВАЛЕВ, подполковник иптәш СЕВАНКОВ, полковник иптәш ДРЯХЛОВ һәм майор иптәш ДУБРОВИН частьлары бәреп керделәр. Шәһәрне алуга, көнбатыштан әйләнеп үтү юлы белән полковник иптәш ШАПКИН һәм майор иптәш ХОДОС частьлары булышлык итте.

II.

КӨНЬЯК-КӨНБАТЫШ ФРОНТ ГАСКӘРЛӘРЕ ВОРОШИЛОВГРАД ҺӘМ КРАСНЫЙ СУЛИН ШӘҺӘРЛӘРЕН АЛДЫЛАР

Армия генералы иптәш Н. Ф. ВАТУТИН командалыгындагы Көньяк-көнбатыш фронт гаскәрләре, бик каты сугышлардан соң, Украинада ВОРОШИЛОВГРАД шәһәрен һәм Ростов өлкәсендә КРАСНЫЙ СУЛИН шәһәрен алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

Москва өлкәсе комсомол активының һәм авыл хуҗалыгы яшь алдынгыларының киңәшмәсе

13 нче февральдә Союзлар йортының колонналы залында Москва өлкәсе комсомол активының һәм авыл хуҗалыгы яшь алдынгыларының киңәшмәсе булды.

ВКП(б) ның Москва Өлкә Комитеты секретаре иптәш **Максимов** 1943 нче елгы авыл хуҗалыгы эшләрендә комсомолның һәм яшьләрнең бурычлары турында доклад белән чыкты.

Иптәш Максимов докладына буенча фикер алышуларда ВЛКСМ ның шәһәр һәм район комитетлары секретарьлары, колхоз председательләре, тракторчылар, звено җитәкчеләре, политбүлек начальникларының комсомол буенча ярдәмчеләре катнашты.

Киңәшмәдә иптәш **М. И. Калинин** речь белән чыкты. Киңәшмәдә катнашучылар аны көчле алкышлар белән каршы алдылар һәм аның речен гадәттән тыш игътибар белән тыңладылар.

Соңыннан киңәшмәдә ВЛКСМ Үзәк Комитеты секретаре иптәш **Михайлов** чыкты.

Киңәшмәдә катнашучылар колхозлардагы, совхозлардагы һәм МТС лардагы барлык яшьләргә һәм комсомолецларга карата хат белән мөрәҗәгать иттеләр. Бу хатларында алар язгы чәчүгә уңышлы әзерләнү һәм аны яхшы итеп үткәрү өчен, бөртекле ашлыклардан һәм яшелчәләрдән югары уңыш алу өчен яшьләрне һәм комсомолецларны большевикларча көрәш алып барырга чакыралар.

Москва өлкәсе комсомолецлары Горький өлкәсенең авыл яшьләрен социалистик ярышка чакырдылар.

Киңәшмәдә катнашучылар, гадәттән тыш күтәренкелек һәм мәхәббәт белән, иптәш Сталинга котлау кабул иттеләр. (ТАСС).

ИПТӘШ М. И. КАЛИНИН ЧЫГЫШЫ

Иптәшләр, соңгы айларда Кызыл Армия фронтта шактый зур уңышларга иреште.

Бу уңышлар Кызыл Армиянең яхшы коралланган булуыннан, аның командирларының батыр һәм инициативалы булуыннан, аның сугышчыларының үз ватаннары өчен үзләрен аямыйча көрәшүләреннән генә килеп чыкмадылар. Безнең армиябездә бу сыйфатлар моннан элек тә бар иде. Соңгы вакытларда безнең Кызыл Армиябезнең аерылып тора торган яңа сыйфаты—күтәренке оешканлыктан гыйбарәт. Армия сугыш тәҗрибәсе алды. Һәр хәзер аның җиңүләре, алар батырлык һәм үз-үзенне аямау җимешләре генә түгел. Аның җиңүләре күтәренке оешканлыкка нигезләнгәннәр. Сугышчылар һәм командирлар сугыш осталыгы алдылар, материаль көчләрне азрак югалтып зур нәтиҗәләргә ирешергә өйрәнделәр.

Быел, сугыш шартларында икенче авыл хуҗалыгы елында авыл комсомолецлары массовый күләмдә катнашачак. Хәзер алар алдында да шулай ук, азрак көч түгеп, күбрәк нәтиҗәләргә ирешү өчен оешканлыкка өйрәнү бурычы тора. Билгеле, комсомолецларда яшьләргә хас булган энергия һәм энтузиазм гаять дәрәҗәдә күп. Яшьләрдә бу сыйфатлар барысы да бар. Ләкин кешедә акрынлык белән рәк туа торган бер сыйфат бар. Ул—оешканлык күнекмәләре, һәрбер эш өчен иң яхшы оештыру формалары таба белү.

Аларны кайда табарга, дип сораулары мөмкин. Бу турыда китаплардан укып белү кыен. Безнең мәктәпләрдә дә, шулай ук, оештыру практикасыннан дәрес бирмиләр, аның методларын һәм детальләрен генә түгел, хәтта төп принципларын да өйрәтмиләр. Оештыру күнекмәләре хезмәттә, эштә, тәҗрибәдә табыла.

Безгә үткән елны авыл хуҗалыгы эшләрен үткәргән чакта нинди кимчелекләр булганлыкны, кирәк булганга караганда күбрәк хезмәт куйганлыгыбызны исәпкә алырга кирәк. Хезмәтне болай әрәм итүне кабатларга ярамаганлыкны исәпкә алырга кирәк.

Мәсәлән, берәр эшне үтәү өчен без кирәк булганга караганда ике тапкыр күбрәк хезмәт биргәнбез дип күз алдына китерик. Билгеле, яхшы эшләдек, заданиене 100 процентка үтәдек, дип әйтерләр. Ләкин шулай булса да күп көчне әрәмгә үткәргәнлегебез бик кызганыч.

Ә бит, иптәшләр, яшьләрнең бурычы барлык авыл хуҗалыгы эшләрен мөмкин кадәр яхшы итеп үтәүдә генә түгел. Шуның белән бергә, яшьләр үзләрен зурларга алмаш итеп әзерлиләр, ә моның өчен аларның көчен сакларга кирәк. Эш тә кайнап торсын, культура үсеше өчен вакыт та калырлык булсын.

Мин уйлыйм, Москва комсомолецлары быел да авыл хуҗалыгы эшләре планын үтәүгә барлык белемнәрен бирү белән генә калмаслар, бәлки шактый күп оештыру тәҗрибәсе дә тупларлар.

Оештыру тәҗрибәсе, оештыру күнекмәсе, ул—кешенең иң яхшы сыйфатларыннан берсе. Бу сыйфат хәзерге вакытта сезнең алдыгызга яңа авыл хуҗалгы елы куя торган максатларга ирешү өчен кирәк булу өстенә, тагын, киләчәктә дә сезгә хезмәт итәр, сезнең тормышыгызда гаять зур роль уйнар.

Оештыру тәҗрибәсе нинди генә заданиене булса да үтәүгә ничек итеп яхшырак якын килергә икәнлекне күрсәтә һәм бу сыйфат сезгә һәрбер эштә ярдәмче булып хезмәт итәр.

Безнең алдыбызда сугыш вакытында да, сугыштан соң да гаять зур эш тора. Бу эш бик күп көч куюны гына түгел, бәлки үзеңнең көчеңне мөмкин кадәр файдалы итеп куллана белүне дә таләп итә.

Москва өлкәсе комсомолецлары һәм яшьләре әнә шуңа өйрәнергә тиешләр дә.

Москва шәһәре һәм Москва өлкәсе комсомолецларының җиңүгә иң аз көч һәм иң аз энергия белән ирешергә мөмкинлек бирерлек тәҗрибә туплауларын телим. Әгәр дә сез бу яктан уңышка ирешсәгез, димәк, партия заданиеләрен, иптәш Сталин заданиеләрен дә үтәрсез диган сүз. **(Көчле кул чабулар. Барысы да урыннарыннан торалар).**

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

14 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРУ

14 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Новочеркасск районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че часть сугышчылары немецларны көчле итеп ныгытылган оборона узелыннан бәреп чыгардылар һәм 6 орудие, 17 пулемет, 4 миномет һәм бик күп сугыш припаслары кулга төшерделәр.

* * *

Шахтыдан көнбатыштарак безнең частьлар сугыша-сугыша алга бардылар. 3 паровоз, 72 вагон, 28 автомашина һәм 4 сугыш припаслары склады кулга төшерелде. Пленныйлар алынды. Н-че часть сугышчылары немецларның бер ротадан артык пехотасын кырып ташладылар һәм 2 танкысын яндырдылар.

* * *

Красноармейское районында безнең частьлар һөҗүм сугышлары алып бардылар. Дошман берничә тапкыр контратакалар ясап карады, ләкин үзе өчен зур югалтулар белән алып ташланды. Бер участокта гына да немецларның моторлаштырылган бер батальон пехотасы тар-мар ителде. Сугыш кырында дошманның 400 гә якын үле гәүдәләре һәм яндырылган 2 танкысы калды.

* * *

Лозовая районында безнең частьлар халык яши торган бер пунктны алдылар. Бу пункт өчен булган сугышларда немецларның 5 танкысы зарарланды һәм яндырылды. 3 танк, 4 орудие һәм бер радиостанция куелган бер автомашина кулга төшерелде. Икенче бер участокта Н-че часть сугышчылары 7 орудие, 22 автомашина, 10 тонна чәнечкеле тимерчыбык, рельслар һәм шпаллар төялгән 19 платформа, күмер төялгән 21 вагон һәм төрле йөкләр төялгән 100 товар вагоны кулга төшерделәр.

* * *

Чугуев районында безнең гаскәрләр, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, алга баруларын дәвам иттерделәр. Хәрәкәттәге Н-че часть халык яши торган берничә пунктны алды. Безнең сугышчылар бер батальонга якын немецларны кырдылар, дошманның 29 танкысын зарарладылар һәм яндырдылар. Икенче бер участокта безнең подразделениеләр халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар һәм бик күп трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Калинин өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отрядына немецларның җәза экспедициясе һөҗүм иткән. Сан ягыннан өстен булган гитлерчылар партизаннарны чолгап алырга һәм юк итәргә маташканнар. Урман юлларында чаңгыларда хәрәкәт итүче совет патриотлары немец солдатларыннан һәм офицерларыннан 90 кешене үтергәннәр һәм 100 дән артык кешне яралаганнар. Немец-фашист карательләр бер нәтиҗәгә дә ирешә алмыйча, чигенгәннәр. Икенче бер отрядның партизаннары немецларның фронт линиясенә бара торган бер эшелонын юлдан чыгарганнар. Һәлакәт нәтиҗәсендә 2 паровоз һәм сугыш йөкләре төялгән 8 вагон һәм 8 платформа җимерелгән.

* * *

Немецлар командованиесе Төньяк Кавказда немец гаскәрләренең җиңелүен бик тырышып яшерергә маташа һәм, элеккечә, «Кавказда фронт линиясен алдан уйланган план буенча кыскарту» турында ахмак экиятләр тарата. Немец хәрби пленныйларының әйткәннәре немецлар командованиесенең бу боргалануларын фаш итәләр. Немецларның 13 нче танк дивизиясенең 93 нче мотополкының 7 нче ротасыннан плен алынган унтер-офицер Гейнц Махлит болай диде: «Безнең дивизия алдына Орджоникидзе шәһәрен алу бурычы куелган иде, дивизия шунда кыш чыгар дип уйланган иде. Русларның һөҗүме башланганнан соң офицерлар, яз көне Грозныйга һәм Бакуга походны дәвам иттерү өчен без ничек кенә итеп булса да позицияләрне саклап калырга тиешбез, дип безгә берничә тапкырлар әйттеләр».

Немецларның 97 нче пехота дивизиясенең 204 нче полкының 13 нче ротасыннан плен алынган солдат Рудольф Мюту болай диде: «Безнең дивизия Туапсега үтәргә, аны алырга һәм бу шәһәрдә үзенә кышкы квартира әзерләргә тиеш иде. Туапсены алып булмады. Шуннан соң, без Майкоп шәһәрендә кышлаячакбыз дип игълан ителде. Бөтенләй көтмәгәндә генә эш башкача булып китте. Руслар безне Кавказда кышкы квартиралардан мәхрум иттеләр».

Немецларның 370 нче пехота дивизиясенең 667 нче полкының 6 нчы ротасыннан плен алынган унтер-офицер Фридрих Лобак болай диде: «Якын араларда ук без Иранга кадәр барып җитәрбез, дип офицерлар бөтен җәй буена әйтеп килделәр. Ләкин без тукталып калдык һәм артык алга китә алмадык. Көз көне дивизия бик тизлек белән ныклы һәм ышанычлы оборона корырга дип югары командованиедән приказ алды. Приказны барлык солдатларга укыдылар. Анда безнең язга кадәр Кавказда калачагыбыз, бу кышның безнең өчен үткән елгы кыштан яхшырак булачагы әйтелгән иде. Русларның һөҗүме безнең өчен бөтенләй көтелмәгән хәл булды. Без руслар болай һөҗүм итә алалар дип уйламаган идек».

14 нче ФЕВРАЛЬДӘ ГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРУ

14 нче февральдә Көньяк фронт гаскәрләре, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп, **Ростов-Дон** шәһәрен алдылар.

Көньяк-Көнбатыш фронт гаскәрләре, бик каты сугышлардан соң, Украинада **Ворошиловград** шәһәрен һәм Ростов өлкәсендә **Красный Сулин** шәһәрен алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

7 нче февральдән 13 енә кадәр үткән атнада һава сугышларында һәм дошман аэродромнарында немецларның 243 самолеты юк ителде. Шул ук вакыт эчендә без 101 самолет югалттык.

1 нче февральдән 12 сенә кадәр булган вакыт эчендә безнең корабльләр һәм авиациябез Баренц диңгезендә дошманның 6 транспортын һәм бер сакчы кораблен батырдылар.

* * *

13 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 200 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 5 артиллерия батареясының утын бастырдылар, бер сугыш припаслары складын һәм бер ягулык складын шартлаттылар һәм бер тимер юл эшелонын җимерделәр.

* * *

Лихая районында безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Бу пунктларның берсе өчен булган сугышта 2 орудие, 5 миномет, танкка каршы ата торган 8 мылтык һәм 22 пулемет кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең сугышчылар бер шахтаны һәм халык яши торган 2 пунктны алдылар. 14 автомашина, бер сугыш припаслары склады һәм бер азык склады кулга төшерелде.

* * *

Ворошиловскидан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр алга уңышлы рәвештә киттеләр. Дошманга каршы сугышларда немецларның бер батальонга якын пехотасы юк ителде. Бик күп трофейлар кулга төшерелде. Трофейларның саны алына.

* * *

Красноармейское районында безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Красноармейское шәһәре өчен булган сугышларда безнең частьлар 2.000 гә якын немец солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр. Күп трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында төрле калибрдагы 20 орудие, 20 танк төялгән эшелон, төрле сугыш милекләре төялгән 10 эшелон, 600 автомашина һәм берничә склад бар. Н-че часть, омтылышлы удар ясап, немецларны халык яши торган бер зур пункттан бәреп чыгарды. Дошманның 200 солдаты һәм офицеры плен алынды.

* * *

Чугуев районында безнең гаскәрләр, дошманның контратакаларын кире кайтарып, алга киттеләр. Н-че часть сугышчылары немецларның 7 танкысын һәм бер ротадан артык пехотасын юк иттеләр. Икенче бер участокта гитлерчылар, зур әһәмияте булган халык яши торган бер пунктны яңадан алырга маташып, контратака ясаганнар иде. Совет сугышчылары дошманга якынрак килергә ирек биреп, соңыннан барлык төр кораллардан ут ачтылар. Немецлар, сугыш кырында 300 гә якын үле гәүдәләрен һәм яндырылган 3 танкларын калдырып, тәртипсез рәвештә чигенделәр.

* * *

Фатеж районында безнең частьлар дошманның халык яши торган бер пунктны саклап торучы бер гарнизонын тар-мар иттеләр. 160 немец солдаты һәм офицеры плен алынды. Трофейлар кулга төшерелде. Н-че берләшмә частьлары алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Безнең сугышчылар, дошманның контратакаларын кире кайтарып, ике рота гитлерчыларны юк иттеләр һәм немецларның 4 танкысын сафтан чыгардылар.

* * *

Сумы өлкәсендә хәрәкәт итүче Тарас Григорьевич Шевченко исемендәге партизаннар отряды кинәт немецлар гарнизонына һөҗүм ясаган. Партизаннар 93 дошман солдатын һәм офицерын кырып ташлаганнар. Трофейлар кулга төшерелгән. Шулар арасында 2 пулемет, 60 винтовка, 15 ат һәм 10.000 патрон бар. Украина партизаннарының икенче бер отряды дошманның өстен көчләренә каршы сугыш алып барган. Совет патриотлары 100 гә якын гитлерчыны кырганнар һәм 40 немец солдатын плен алганнар.

* * *

Ростов өлкәсенең Романовская станицасында немец-фашист кабахәтләр совет гражданнарын ерткыч төстә газаплатаннар һәм җәзалаганнар: кулларын сындырганнар, күзләрен тишеп чыгарганнар. Хәзер гитлерчылардан азат ителгән бу станицаның кешеләре совет патриотларының үзләрен батырларча тотулары турында сөйлиләр. Фашист бандитлар Валентин Тюховны атарга алып киткәч, ул: «Яшәсен Совет ватаныбыз!» дип бөтен көче белән кычкырган. Совет хезмәткәре Кожанов, җәзалап үтерелер алдыннан палачларның йөзенә туры карап, болай дип кычкырган: «Исәпләшү сәгате ерак түгел. Безнең җирдә сез эшләгән әшәкелекләрнең бөтенесе өчен Кызыл Армия сездән үч алыр, фашист җыланнар!».

* * *

Югославия патриотлары немец-итальян оккупантларга каршы бик каты сугышлар алып баралар. Айдовекта партизаннар итальян гарнизонын тар-мар иткәннәр һәм 70 кешене плен алганнар. Рисовац—Горня Сухая участогында партизаннар 3 көн дәвам иткән сугышларда 400 гә якын гитлерчыны кырып ташлаганнар. Плитвице районында немецларның 6 танкысы шартлатылган. Майки һәм Чапле якынында партизаннар немецларның чолганып алынган группасын юк итү сугышлары алып баралар.

ЯГУЛЫККА ҺӘМ ЭЛЕКТР ЭНЕРГИЯСЕНӘ ЭКОНОМИЯ БУЕНЧА ШӘҺӘР ПРЕДПРИЯТИЕЛӘРЕНЕҢ ЯРЫШ ЙОМГАКЛАРЫ

Шушы көннәрдә ВКП(б) шәһәр комитеты бюросының, хезмәт ияләре депутатларының шәһәр советы башкарма комитеты белән берлектә, утырышы булды. Утырышта ягулыкка, җылылык һәм электр энергиясенә экономия буенча 1942 нче елның 4 нче кварталында шәһәр предприятиеләре арасында җәелдерелгән социалистик ярышка йомгак ясалды.

Ярыш барышында 5.300.000 киловатт-сәгать электр энергиясенә һәм 4.500 тоннага якын ягулыкка экономия ясалган. Бу вакыт эчендә күпчелек предприятиеләрдә ягулыкка һәм энергиягә экономия мәсьәләсенә игътибар көчәйтелде. «ФИ» косинусы шактый артты, энергия хуҗалыкларының торышы яхшырды, энергия хуҗалыклары работникларының квалификацияләре күтәрелде.

Хезмәт ияләре депутатларының шәһәр советы башкарма комитеты һәм ВКП(б) шәһәр комитеты бюросы 1942 нче елның 4 нче кварталындагы ярыш йомгаклары турында жюриның карарын раслады. Жюри карары буенча ярышта, беренче урынны баш инженеры иптәш Корнеев булган завод, икенче урынны баш инженеры иптәш Касаткин булган завод һәм «Спартак» комбинаты, өченче урынны партоешма секретаре урынбасары иптәш Ставер булган завод, Казан мех комбинаты һәм баш инженеры иптәш Зафьянцев булган завод алдылар. Бу җиңүче заводларның коллективларына байрак һәм грамоталар тапшырылачак.

Предприятиеләрнең партия һәм хуҗалык работниклары ягулыкка һәм энергиягә экономия буенча эшне киң җәелдерергә, 1943 нче елның 1 нче январена тотылган күләм белән чагыштырганда ягулыкка, җылылык һәм электр энергиясенә 1943 нче елның 1 нче маена кадәр 10 процент экономия ясау бурычын куярга тиешләр.

Предприятиеләрдә җылылык хуҗалыгының эксплоатациясенә игътибарны көчәйтергә, җылылык энергиясенең эшләнешен һәм тотылуын учетка алуны юлга салырга, суга һәм парга контроль үлчәү приборлары куярга һәм башка төрле оештыру-техника чараларны үткәрергә кирәк.

ВКП(б) райкомнарының секретарьлары һәм ВКП(б) шәһәр комитетының тармаклар буенча секретарьлары ягулыкка һәм энергиягә экономия өчен социалистик ярышны киләчәктә тагын да кинрәк җәелдерү эшенә җитәкчелекне тәэмин итәргә, ярышка шәһәрдәге барлык предприятиеләрнең һәм электр станцияләренең тартылуына ирешергә тиешләр.

БЕЛОРУССИЯ ПАРТИЗАННАРЫНА 15.000 АПТЕЧКА

Казандагы 11 нче номерлы фармзавод бик күп патриотик эш күрсәтте: махсус рәвештә Белоруссия партизаннары өчен 15.000 аптечка әзерләп җибәрде. Бу зур һәм мөһим чараны кыска вакытта һәм уңышлы үткәрүе өчен ВКП(б) ның шәһәр комитеты завод коллективына рәхмәт белдерде.

РУЗВЕЛЬТНЫҢ ЧЫГЫШЫ

ВАШИНГТОН, 13 февраль. (ТАСС). Йортта хәбәрчеләр ассоциациясенә мөрәҗәгать итеп, Рузвельт болай диде:

— Моннан ике ел элек, Пирл-Харборда булган вакыйгалардан күп айлар элек, Американың демократия арсеналы булырга карар биргәнлеге турында әйткән идем. Ул чагында барлык америкалылар цивилизацияне варварлардан коткару эшендә тулысынча катнашырга карар биргәннәр иде. Шул чагында ук инде без тарихи бурычны үтәү белән якыннан ук шөгыльләнә башлаган идек. Америка халкы бу бурычны бик уңышлы рәвештә башкарып чыкты. Бу—производство мәсьәләсе иде. Бүген безнең башыбызда бу бер фикер тора. Бу—сугышны ахырынча, ягъни берләшкән милләтләр гаскәрләренең Берлин, Рим һәм Токио урамнары буйлап тантаналы марш белән үтүләренә кадәр дәвам иттерергә безнең карар иткән булуыбыз.

Үткән елның сентябрендә мин үз илебездә инспекция сәяхәтендә булдым. Мин үзебезнең хәрби заводларны эшләп торган хәлдә күрдем, армиянең һәм флотның өйрәнү лагерьларын, аэродромнарны күрдем. Мин америкалыларның—ирләрнең һәм хатын-кызларның, администрация вәкилләренең дә, шулай ук эшчеләрнең дә, производство планнарын арттырып үтәү өчен барлык көчләрен бирүләрен күрдем. Мин Америка солдатларының, моряклары-ның һәм очучыларының алдагы көрәшкә әзерләнүләрен күрдем. Хәзер мин океан артындагы фронтларның берсеннән кайттым. Анда Америка заводларында эшләнгән продукция һәм Америка лагерьларында әзерләнгән кешеләр дошманга каршы сугыш хәрәкәтләрендә практик төстә катнашалар. Мин сугыш кырында үзебезнең гаскәрләребезне күрдем. Мин Тринидадта, Белемдә, Натальда, Бразилиядә, Либериядә, Гамбиядә үзебезнең кешеләрне күрдем. Мин Төньяк Африкада үзебезнең ирләребезне һәм кайбер Америка хатын-кызларын күрдем. Анда сугыш бара. Бу кешеләр сугыш беткәнчегә кадәр үк күпләренең үзләренең тормышларын бирергә тиеш булачакларын беләләр. Ләкин шулай ук алар үз илләре дошманнарының куәтен юк итү өчен, чыннан да озакка сузылачак тынычлык өчен һәм киләчәктәге яхшы тормыш өчен көрәшүләрен дә беләләр. Без фронттагы кешеләребезгә гаять дәрәҗәдә ышанабыз һәм аларга карата бездә зур өметләр бар. Бу ышануга һәм бу өметләргә алар лаеклылар. Шул ук сүзләрне безнең флотыбызга карата да әйтергә кирәк. Бу флот булмаганда Американың экспедиция армиясе чит ярларга куркынычсыз төшә алмас иде. Шул ук сүзләрне сәүдә флотының кешеләр составына карата да шул ук дәрәҗәдә әйтергә кирәк. Бу флот яшәү өчен әһәмиятле булган кораллар ташый. Шул кораллар булмаганда, Кушма Штатлар да, безнең союзникларыбыз да көрәшне дәвам иттерә алмаслар иде. Америкалылардан бер генә кеше дә бу солдатларга һәм морякларга гаять көчле тәэсирләнү һәм горурлык хис итмичә, алар каршында үзенең тирәнтен җаваплы икәнлеген хис итмичә карый алмый.

Минем сәяхәтемне сер итеп тотарга кирәк булганлыктан мин булган барлык урыннарда безнең кораллы көчләребезнең кешеләр составы минем килеп чыгуыма бик гаҗәпләнде. Шундый ук көтелмәгән визитларны мин сугыш операцияләренең башка районнарындагы—Тын океан атауларында, Австралиядә һәм Аляска районы атауларында, Атлантик океанда, һәр ике Гвианада, Панама каналы зонасында булган хәрби диңгез базаларындагы, Исландиядәге, Англиядәге, Үзәк Африкадагы, Урта Көнчыгыштагы, Һиндстандагы, Бирмадагы һәм Кытайдагы солдатларыбызга да ясарга теләр идем. Мин аларга алар алып бара торган гаять зур эш өчен, безнең дошманнарыбызны акрынлап, ләкин ышанычлы рәвештә буа торган боҗраны кысуда ярдәм иткән өчен хөкүмәтнең һәм халыкның горурлануларын турыдан-туры әйтергә мөмкинлегем булуны теләр идем. Сез һәрбер батальонда, һәрбер пароход экипажында Американың бик күп төрле гражданнарын, төрле профессияләр вәкилләрен, халыкның төрле катлаулары вәкилләрен, төрле милләт кешеләрен, төрле дин тотучыларны, төрле политик карашлы кешеләрне табарсыз. Сез алардан, нәрсә өчен көрәшәсез, дип сорагыз һәм аларның һәрберсе: «Мин үз илем өчен сугышам» дип җавап бирер. Сез алардан болай дип әйтү белән чынлыкта нәрсәне күздә тотасыз, дип сорагыз һәм сез беренче караштан бер-берсенә бөтенләй ошамаган җаваплар алырсыз. Берсе, мин үзем сөйләргә теләгән нәрсәләрне сөйләү хокукы өчен, үземә ошаган нәрсәләрне уку һәм тыңлау хокукы өчен сугышам, дияр. Икенчесе, мин үземнең эльм-стриттагы баптистлар чиркәвем өстендә нацистлар свастикасы җилфердәүне беркайчан да күрергә теләмәгәнлектән көрәшәм, дияр. Өченчесе, эшләү, үзе өчен һәм семьясы өчен, якын кешеләре өчен иртәнге, көндезге һәм кичке аш яулап алу хокукы өчен көрәшәм, дияр. Дүртенче солдат, минем балаларым һәм аларның балалары яңадан бу күңелсез эш белән шөгыльләнү өчен Европага, Африкага һәм Азиягә китәргә тиеш булмасыннар дип көрәшәм, дияр. Ләкин чынлыкта бу җаваплар барысы да бер үк нәрсәне аңлаталар: һәрбер америкалы азатлык өчен көрәшә.

Бүгенге көнне һәрбер америкалының үзенең һәм аның семьясының азатлыгы башка илләрдәге күршеләренең азатлыгына бәйләнгән, ә киләчәктә ул аңа тагын да күбрәк бәйләнгән булачак. Хәзер бөтен дөнья тоташ бер бөтеннән гыйбарәт. Менә шуңа күрә дә бик ерак булып күренгән районнарда башланган бу сугыш барлык континентларга һәм күпчелек атауларга җәелеп, бөтен кешелек дөньясының тормышына һәм азатлыгына кагылды. Әгәр дә сугыштан соң булачак тынычлык бөтен кешелек дөньясының тоташ бер бөтен булуына нигезләнмәсә һәм гомуми гаделлекне тәэмин итмәсә, ул чагында яңадан бөтен дөнья сугышы микроблары кешелек дөньясына һәрвакыт куркыныч тудырып торачаклар.

Безнең күп солдатларыбыз һәм морякларыбыз ил эчендәге хәл турында борчылалар. Аларга монда, илнең эчендә, тиешеннән артык күп зарланулар ишетелү һәм сугышның чын таләпләрен тиешеннән артык аз аңлау турында һәртөрле күпертелгән һәм ялган хәбәрләр килә. Мин әйтер идем, бу хәбәрләрнең күпчелеге бик нык арттырылган, Америка халкы, гомумән, бу сугыш белән мәшгуль, аңа бөтен җаны-тәне белән булышлык итә. Мин кайбер вөҗдансыз кешеләрнең, политиканнарның һәм публицистларның үз интересларын яки комсызлыкны милләтләр интересларыннан югарырак куйганлыкларын безнең гаскәрләребез алдында инкар итә алмадым. Хәер, бәхеткә каршы, бу кешеләрнең саны бик аз. Безнең гаскәрләр нацистларның, фашистларның һәм японнарның кайбер америкалылар арасында ялган пропаганда таратырга маташуларын беләләр.

Хәзер без бу сугышта иң зур бәрелешләрнең берсен башлау өчен Төньяк Африкага Англия, Франция һәм Америка армияләрен туплыйбыз. Тунис өчен бара торган сугышта дошманның максаты, нинди генә корбаннар биреп булса да, үзенең Африкадагы актык ныгытмасын тотып калудан һәм безгә нацистлар хакимлеге астындагы Европага бара торган бугазларга хуҗа булуда комачаулаудан тора. Тунис өчен бара торган сугышта безнең төп максатыбыз—дошманны диңгезгә алып ташлау. Бу сугышта Англиянең генерал Андерсон командалыгында катнашучы беренче армиясе составында Фландриядә һәм Дюнкеркта булган сугышларның күп ветераннары бар. Бу кешеләрнең нацистлар белән үзләренең исәпләре бар. Англиянең генерал Монтгомери командалыгындагы 8 нче армиясенең күрсәткән мәңгелек хезмәте—маршал Роммель армиясен тар-мар итүдән һәм аны нацист-фашистларның элек җиңүче булган кораллы көчләрен 1.500 миль ераклыкка куып баруыннан гыйбарәт. Тунисста бу бөек 8 нче армия һәм Франция гаскәрләре көньяктан дошманга атака ясаячаклар. Генерал де Голль офицерларыннан берсе булган генерал Леклерк командалыгындагы француз гаскәрләре Сахара аркылы гүзәл кичеш ясадылар. Дошманга көнбатыштан генерал Жиро командалыгындагы француз гаскәрләре белән берлектә Англиянең һәм Американың берләшкән көчләре атака ясаячак.

Бу кораллы көчләрнең бөтенесенә генерал Эйзенхауэр командалык итә. Эйзенхауэрның күрсәткән хезмәтләренә югары бәя бирелде. Касабланкада Англия хөкүмәте, Черчилль аркылы, союзникларның киләчәктәге бөек операцияләренә верховный командующийлык постына аның кандидатурасын тәкъдим итте. Генерал Эйзенхауэрның урынбасары генерал Александер—Англиянең иң бөек сугышчыларыннан берсе. Генерал Александер Англиянең Якын Көнчыгыштагы барлык кораллы көчләренә, шулай ук Эль-Аламейн янында булган хәлиткеч сугышны отып чыккан 8 нче армиягә дә командалык итте. Бу операцияне һәм шуның артыннан булган гаять зур алга китүне ул һәм генерал Монтгомери эшләделәр. Хәзер, мин монда сөйләгән чакта генерал Александер, генерал Эйзенхауэр белән бергәләп, яңа хәрби операцияләр планнары эшлиләр. Бу гаять әһәмиятле фактлар берләшкән милләтләрнең хезмәттәшлеген генә түгел, бәлки аларның бергәләшеп актив эш алып баруларын да раслыйлар. Безнең дошманнарыбыз бу фактларны тиешенчә исәпкә алсыннар. Безнең Тунистагы солдатларыбыз яхшы өйрәтелгәннәр һәм коралланганнар, ләкин алар әле куәтле дошманнарга каршы чын сугышка беренче тапкыр керәчәкләр. Без Германиянең иң яхшы гаскәрләрен Аргон урманнары һәм Маас елгасы аркылы куган генерал Першинг командалыгындагы яшь америкалылар үзләрен ничек тоткан булсалар, бу солдатларыбызның да үзләрен шундый батыр һәм лаеклы төстә тотачакларына тәмам ышана алабыз. Тунис өчен сугышта безгә күп кешеләрне югалтырга туры киләчәк. Бу фактка без үз солдатларыбыз сугышта күрсәтә торган кебек тыныч батырлык белән карарга тиешбез. Дошманның шактый күп көчләре бар һәм ул ныклы позицияләрдә тора. Ул үзенең тәэмин юлларын зур югалтулар биреп саклый, ләкин Гитлер бу югалтуларга барырга риза, чөнки ул Тунисста союзникларның җиңүе нинди нәтиҗәләр бирәчәкне белә. Бу нәтиҗәләр Европага чыннан да басып керүдән гыйбарәт булачак. Без үзебезнең шулай басып керергә уйлавыбызны яшермибез. Германиягә һәм Италиягә бертуктаусыз һәм һәрвакыт көчле рәвештә басым ясалачак.

Көнчыгышта русларның армияләре дошманга җимергеч ударлар ясыйлар. Без дә көнбатышта шуны эшләргә тиешбез. Дошман барлык юнәлешләрдә дә көчле ударлар алырга тиеш, ул үзенең фронты кайда һәм тылы кайда икәнлекне белмәскә тиеш. Франциядән читтә булган барлык французлар бөек бер максат белән—Францияне һәм басып алучылар табаны астында газап чигүче бөтен француз халкын тулысынча азат итү максаты белән берләшәчәкләренә карата Касабланкада тулы ачыклык кертелде. Үзләренең азатлыклары өчен көрәшергә мөмкинлек алган барлык французларны үз-үзләрен корбан итү рухы көннән-көн күбрәк берләштерә бара. Безнең демократик илләребез кулланып эш итә торган төп принципның нигезе Америка һәм Франция революцияләре елларында салынды. Бөтен демократик системаның нигез ташы, хөкүмәткә властьны халык һәм бары тик халык кына бирә дигән принциптан гыйбарәт. Сугышта безнең максатларыбызның берсе—Атлантика хартиясендә әйтелгән максатларның берсе, басып алынган илләрдәге халыкларга яңадан үз язмышларына үзләре хуҗа булырга мөмкинлек бирә торган шартлар тәэмин итүдән гыйбарәт. Басып алынган илләрдәге халыкларга үзләренең изге хокукларын кайтарырга берләшкән милләтләрнең ныклы карар биргән булулары турында бернинди дә шик булырга мөмкин түгел. Франциянең суверенитеты Франция халкының үзенеке. Бу суверенитетны тормышка ашыруны Германия оккупациясе вакытлыча туктатты. Берләшкән милләтләрнең җиңүчән армияләре гомуми дошманны куганнан соң французлар үзләре теләгән хөкүмәтне төзерләр. Хөкүмәтне сайлау тулысынча ирекле булыр. Дөньяда үзенә нинди хөкүмәт сайлап кую мөмкинлеге булган милләтләрнең берсе дә идарә итүнең фашистлар яки нацистлар формасына да, Япониянең сугыш чукмарлары урнаштырган формага да буйсынмас. Мондый идарә формалары, алар—властьны басып алу һәм азатлыкны кисү нәтиҗәләре. Шунлыктан берләшкән милләтләр, тулы хокук белән, идарәнең бу формалары турында берничә гади сүз, ягъни, «Алар моннан соң беркайчан да яшәмәсләр» дигән сүзләрне әйтә алалар. Атлантика хартиясендә мөстәкыйльлек турында әйтелгән хокук нинди булса да хөкүмәт массовый суеш ясый ала дигән сүз түгел, һәм ул бу хөкүмәткә үз халкын яки дөньядагы башка халыкларны колларга әйләндерү хокукын бирми. Бөтен дөнья ышанып торсын, бөтен дөньяда шул кадәр күп кешеләрне корбан итә торган хәзерге тоталь сугыш җир шарында кайда гына булса да квислингларны һәм ловальларны власть башында саклап калу максаты белән яки хәтта шул турыда бик аз гына булса да уйлау белән дә алып барылмый.

Касабланкада кабул ителгән карарлар һәм анда эшләнгән практик планнар сугышның нинди булса да бер мәйданы яки бер континент белән, бер океан яки бер диңгез белән генә чикләнмиләр. Касабланкада булган конференциянең бик күп яңалыклар биргәнлеген һәм бу яңалыкларның немецлар, итальяннар һәм японнар өчен начар яңалыклар булачагын шушы ел беткәнчегә кадәр бөтен дөнья сүзләрдән бигрәк эшләрдә күрер. Күптән түгел без Тын океанның көньяк-көнбатыш өлешендә озакка сузылган һәм авыр сугышны тәмам иттек. Без сизелерлек уңышларга ирештек. Бу сугыш үткән җәйне Соломон атаулары янында һәм Яңа Гвинеяда башланды. Ул авиация өлкәсендә безнең көчләребез өстен икәнлекне һәм аннан да бигрәк, безнең солдатыбызның һәм морягыбызның хәрби сыйфатлары өстен икәнлекне күрсәтте. Американың Тын океанның көньяк-көнбатыш өлешендәге кораллы көчләре Австралиядән, Яңа Зеландиядән, шулай ук турыдан-туры Англиядән зур ярдәм алалар. Без Японияне тәмам тар-мар итү өчен Тын океанның гаять киң мәйданнары аркылы дюймлап-дюймлап кына, бер атаудан икенче атауга акрынлап кына күчүгә кирәк булган кадәр вакыт үткәрергә уйламыйбыз. Японнарга каршы аларны Кытайдан куып чыгару теләге белән хәлиткеч зур хәрәкәтләр эшләнәчәк. Кытайда һәм Япониянең үзенә каршы зур һава хәрәкәтләре булачак. Касабланкада булган сөйләшүләр Чунцинда генерал Арнольд белән генералиссимус Чан Кай-ши арасында дәвам иттерелделәр һәм һөҗүм операцияләренең мәгълүм планнарын эшләү белән тәмам булдылар. Турыдан-туры Токиога алып бара торган күп юллар бар. Без аларның берсен дә игътибарсыз калдырмабыз.

Күчәр державалары пропагандистлары котылгысыз һәлакәтне булдырмый калырга маташып, берләшкән илләрне аеру өчен үзләренең барлык иске трюкларыннан файдаланалар. Алар, әгәр дә без сугышта отып чыксак, ул чагында Россия, Англия, Кытай һәм АКШ, эт белән мәче шикелле үзара сугыша башлаячаклар дип күрсәтергә тырышалар. Бу аларның союзникларны берәмләп-берәмләп кыйнарга мөмкин булыр дип юкка гына өметләнеп, бер дәүләтне икенчесенә каршы котыртуга булган актык маташулары. Алар, безнең арадан кем булса да шул кадәр бер катлы һәм шул кадәр онытучан булып чыгар, аны безнең союзниклар исәбенә «алыш-биреш» ясарга мәҗбүр итеп, алдарга мөмкин булыр дип юкка гына өметләнәләр. Аларның үз җинаятьләренең нәтиҗәләреннән котылып калырга мондый пакьхалы маташуларына без болай дип җавап бирәбез:

— Безнең нинди булса да күчәр державасы белән яки күчәр державаларының кайсы булса да бер өлеше белән нинди булса да эш алып баруыбызның бердән-бер шарты «һичбер сүзсез капитуляция» турында Касабланкада игълан ителгән шарт. Барлык берләшкән илләр шулай дип белдерәләр. Шушындый килешмәүчән политика алып барганыбыз хәлдә без күчәр илләрендәге гади халыкка зыян китерергә уйламыйбыз. Ләкин без күчәрнең варвар җитәкчеләренә тулысынча тиешле җәзаны бирүгә һәм алардан үч алуга ирешергә уйлыйбыз. Әгәр дә нацистлар, нинди булса да пропаганда ярдәме белән Англия, Америка яки Кытай хөкүмәтләрен һәм халыкларын Россиягә каршы яисә Россияне безнең бөтенебезгә каршы кузгата алырбыз дип уйлыйлар икән, алар чыннан да ахмаклар. Рус армиясенең басып алучыларга каршы торып, аларны артка алып ташлап искиткеч батырлык һәм нык торучанлык күрсәткән булуы һәм Сталин әфәнденең һәм аның хәрби начальникларының бөек рус армияләренә җитәкчелек итүдәге даһилыклары—болар үзләре өчен үзләре сөйлиләр. Сугыш трагедиясе барлык берләшкән милләтләрнең хөкүмәтләрендә һәм халыкларында сизгерлекне кискенләштерде һәм мин шул нигездә әйтә алам, аларның сугыштан соң даими тынычлык тәэмин итү өчен үзләренең бердәмлекләрен саклап калулары чиктән тыш кирәк икәнлекне аңлаулары миңа бик яхшы билгеле.

Сез тулысынча ышана аласыз, әгәр дә күчәр державалары арасыннан беренче булып Япония егылса, ул чагында барлык берләшкән милләтләрнең тырышлыклары һәм ресурслары Германияне җимерү бурычына тупланган булачак. Икенче яктан, безнең сугышны бөтен дөньяда тулы җиңүгә ирешкәнчегә кадәр алып баруыбыз турында нацистларда яки японнарда берәр төрле шик тумасын өчен баш министр Черчилль шушындый рәсми килешү төзергә теләде: әгәр дә Германия Япониядән алда җиңелсә, ул чагында, билгеле, Британия империясенең барлык ресурслары һәм барлык кешеләр резервлары Япониягә тулысынча һәм соңгы ударны ясау өчен Кытай белән берләшерләр.

Мин аңа бу мәсьәлә буенча бернинди

(Ахыры 4 нче биттә).

Совет информбюросыннан

15 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

15 нче февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Лихая районында безнең гаскәрләр уңышлы рәвештә алга киттеләр. Халык яши торган зур бер пункт өчен булган сугышларда Н-че берләшмәнең частьлары немецларның 26 танкысын җимерделәр һәм яндырдылар. 9 паровоз һәм төрле хәрби йөкләр төялгән 150 вагон кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең сугышчылар 7 орудие, 15 немец танкысы, 68 автомашина, 7 паровоз, 500 вагон, бер склад ашлык һәм 3 склад агач материаллары кулга төшерделәр.

* * *

Ворошиловскидан көньяк-көнбатыштарак безнең частьлар сугыша-сугыша алга киттеләр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Бик каты сугышларда немецларның 5 танкысы һәм бер батальонга якын пехотасы юк ителде.

* * *

Чугуев районында безнең гаскәрләр бик каты һөҗүм сугышлары алып бардылар. Дошман, совет гаскәрләренең алга баруларын тоткарларга маташып, сугышка үзенең сайланма частьларын, шул исәптән күптән түгел генә Франциядән китерелгән эсэсчылар дивизиясен кертә. Безнең частьлар дошманның каршылык күрсәтүен җиңәләр һәм аның җанлы көчләренә, техникасына зур югалтулар китерәләр. Сугышларның өч көне эчендә Н-че берләшмәнең частьлары немецларның 62 танкысын яндырдылар һәм җимерделәр, 1.200 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын юк иттеләр. Икенче бер участокта немецлар 15 танкларын контратакага җибәрделәр. Безнең сугышчылар дошманның 11 танкысын юк иттеләр, ә калган 4 танк тиз генә качтылар.

* * *

Золочев районында безнең гаскәрләр, һөҗүмне дәвам иттереп, халык яши торган бер пунктны алдылар. Немецлар үзләре югалткан оборона чиген кире кайтарырга маташып, берничә контратака ясадылар. Н-че частьның сугышчылары дошманның барлык контратакаларын кире кайтардылар һәм аны зур югалтуларга дучар иттеләр.

* * *

Курскидан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че берләшмәнең частьлары халык яши торган бер зур пунктны алдылар, бу пункт өчен булган сугышларда немецларның 200 гә якын солдат һәм офицерын юк иттеләр, 12 орудие, 15 автомашина һәм 3 тягач кулга төшерелде.

Ростов өлкәсе районнарыннан берсендә хәрәкәт итүче партизаннар отряды немецларның сугыш припаслары төялгән бер эшелонын шартлаткан. Немец басып алучыларга каршы сугышларда партизаннар отряды 50 гитлерчыны кырып ташлаган һәм 3 мотоцикл, 46 винтовка, 3 мең патрон, 8 повозка, 10 ат 1.000 баштан артык эре мөгезле терлек һәм бер зур склад ашлык кулга төшергән. Ростов партизаннарының икенче бер отряды бер авылда немецлар гарнизонына һөҗүм иткән һәм андагы гитлерчыларны кырып бетергән. 5 автомат, 40 винтовка, 4 мең патрон, 65 бинокль, 80 ат һәм азык тутырылган бер склад кулга төшерелгән.

* * *

Дошманнан азат ителгән Ново-Максимовский хуторында тәрәзәләре кирпеч белән томаланган һәм ишекләре кадаклангән ике таш йорт безнең сугышчыларның игътибарын үзенә тартты. Бу йортларның эчләрендә ярым чергән 60 үле гәүдә һәм үлем хәлендә булган 16 кызылармеец табылды. Хәзер билгеле булганча, немецфашист кабахәтләр бер группа яраланган кызыларармеецларны пленга алганнар, аларны терелэй томалап куйганнар. Кешеләр акрын һәм газаплы үлем белән һәлак булганнар. Кызыл Армиянең килеп җитүе, исән калган кызылармеецларны котылгысыз һәлакәттән коткарды.

15 нче ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

15 нче февральдә Украинада безнең гаскәрләр Краснодон шәһәрен, Успенка район үзәген, зур тимер юл станциясе Лутугиноны, тимер юл станциясе Верхне-Дубаннаяны алдылар.

Ростов өлкәсендә безнең гаскәрләр район үзәге Родионов-Несветайскоены, халык яши торган зур пунктлардан Кутейниковоны, Большие Салыны алдылар.

Орел өлкәсендә безнең гаскәрләр Дросково район үзәген һәм халык яши торган башка пунктларны алдылар.

Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

Баренц диңгезендә безнең корабльләр дошманның 19.000 тонна авырлыктагы 2 транспортын батырдылар.

* * *

14 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 8 артиллерия батареясының утын бастырдылар һәм 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар.

* * *

Красный Сулиннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр сугыша-сугыша алга бардылар һәм халык яши торган 30 пунктны немец басып алучылардан азат иттеләр. Бер аэродромда немецларның 2 төзек самолеты кулга төшерелде. Н-че часть сугышчылары немецларның бер батальонга якын пехотасын кырдылар, 4 танкысын юк иттеләр, 6 орудие, 2 миномет һәм сугыш припаслары төялгән 28 автомашина кулга төшерделәр.

* * *

Ворошиловскидан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть дошманны халык яши торган бер зур пункттан бәреп чыгарды һәм 200 гитлерчыны кырып ташлады. Трофейлар, шул исәптән 12 орудие, 31 автомашина, бер сугыш припаслары склады һәм бер корал склады кулга төшерелде.

Красноармейское районында безнең гаскәрләр каты һөҗүм сугышлары алып бардылар. Дошман берничә тапкыр контратакалар ясап карады, ләкин алар дошман өчен зур югалтулар белән кире кайтарылдылар. Н-че часть сугышчылары 18 паровоз, 500 вагон, 1.500 автомашина, 100 мотоцикл, 1 азык склады һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. Икенче бер участокта дошман пехотасы танклар ярдәме белән контратакага күчкән иде. Командиры лейтенант Костров булган батареяның артиллеристлары, орудиеләрне ачык позициягә алып чыгып һәм туры атып, немецларның 7 танкысын һәм 2 бронемашинасын сафтан чыгардылар.

Иптәш Грецун подразделениесе гвардеецлары үзләренә мәңгелек дан казандылар. Алар, дошманның күп кенә ныгытылган точкаларын алып, гитлерчыларның берничә тапкыр ясалган бик каты атакаларын кире кайтардылар. Шуннан соң фашистлар фронттан контратака ясап, автоматчиклар төялгән 26 танкларын подразделение командирының политик эш буенча урынбасары иптәш Поляков командалыгындагы взвод саклап тора торган флангка җибәрделәр. Хәл чиктән тыш кискенләште, ләкин 17 гвардеец дошманны кыюлык белән каршы алдылар. Сугышның беренче минутларында ук немецларның 8 танкысы яндырылды. Безнең 17 гвардеец тигезсез сугышта һәлак булдылар, ләкин хәрби бурычны намус белән үтәделәр. Алар дошманның бер генә танкысын да үткәрмәделәр һәм шулай итеп үз частьларына уңышны җәелдерергә һәм гитлерчыларны алып ташларга мөмкинлек бирделәр.

* * *

Чугуев районында безнең гаскәрләр каты һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че берләшмә частьлары эсэсчыларның бер-бер артлы ясалган 3 контратакасын кире кайтардылар. Сугыш кырында дошманның йөзләрчә үле гәүдәләре һәм сафтан чыгарылган 6 танкысы калды. Икенче бер участокта безнең танкистлар, дошман пехотасының бер колоннасын тар-мар итеп, 17 орудие, 100 автомашина һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Англиянең «Дейли экспресс» газетасы үзенең Стакһольмдагы хәбәрчесенең түбәндәге хәбәрен басып чыгарды: «Рус фронтыннан Германиянең берничә СС дивизиясе алынган. Кайбер кешеләр, барлыгы 40 дивизия алынган дип исәплиләр... Бу частьлар Германиягә һәм оккупацияләнгән илләргә җибәреләләр».

«Дейли экспресс» хәбәрчесенең бу сүзләре чынлыкка бөтенләй капма-каршы килә. 1943 нче елның 31 нче январенда Совет Информбюросы, немецлар командованиесенең моннан элек көнбатыштан китерелгән гаскәрләрдән тыш, ноябрь азагыннан башлап көнбатыштан совет-немец фронтына тагын 19 пехота дивизиясе һәм 33 танк дивизиясе җибәргәнлеген, шул исәптән 11 дивизиянең Германиядән һәм 11 дивизиянең Франциядән, Бельгиядән һәм Норвегиядән китерелгәнлеген хәбәр иткән иде. Болардан тыш немецларның 9 дивизиясе көнбатыштан совет-немец фронтына юлда киләләр иде. 31 нче январьдан бирле үткән вакыт эчендә немецларның бу 9 дивизиясеннән 6 сы инде совет-немец фронтындагы сугышларда күренделәр. Шушы елның 31 нче январеннан соң Франциядән совет-немец фронтына килгән дивизияләрнең номерлары һәм исемнәре түбәндәгечә: 711 нче, 335 нче, 257 нче һәм 333 нче пехота дивизияләре, «Рейх» һәм «Адольф Гитлер» исемле СС танк дивизияләре. Совет гаскәрләре немецларның бу берләшмәләрен җитди югалтуларга дучар иттеләр һәм бу дивизияләрнең барысыннан да пленныйлар алдылар.

Немецлар командованиесе, совет-немец фронтында үзенең эшен рәтләргә омтылып, Франциядән һәм башка оккупацияләнгән илләрдән үзенең дивизияләрен алырга һәм аларны көнчыгышка җибәрергә мәҗбүр. «Дейли экспресс» газетасы исә, чынлыкка һич тә туры килми торган чыгышлар белән, җәмәгатьчелек фикерен ирекледәнме яки ирексездәнме буталышка кертә.

ПРОФСОЮЗ-КОМСОМОЛ ЧАҢГЫ КРОССЫ

КАЗАНДА КРОССНЫҢ БЕРЕНЧЕ КӨНЕ

14 нче февральдә Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә профсоюз-комсомол чаңгы кроссы башланды.

Быелгы кросста чаңгычылар 20 сәгатьлек программаны үтәләр.

Беренче көндә Казанда 10 меңнән артык чаңгычылар стартка чыктылар. Бауман районында кросста катнашучыларның 82 проценты ГТО һәм БГТО нормативларын үтәделәр. Бу уңышлар быелгы кыш көнендә районлардагы комсомол һәм физкультура оешмаларының зур тренировка эшләре алып барганлыкларын күрсәтә.

Горький исемендәге культура һәм ял паркында ватан сугышыннан яраланып кайткан һәм хәзер сәламәтләнгән сугышчыларның ярышлары үткәрелде.

Шәһәр мәктәпләрендә һәм һөнәр училищеларында укучылар кросста зур энтузиазм белән катнашалар.

Кроссның беренче көнендә чаңгы ярышларында катнашучыларның 73 проценты ГТО һәм БГТО нормаларын тапшырды. Бу кросс 1 нче мартка кадәр дәвам итәчәк.

А. ВОЙНОВ.

КРОССКА 3.500 КЕШЕ КАТНАША

ШӨГЕР. (Телефон буенча). Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән үткәрелә торган профсоюз-комсомол чаңгы кроссына районда 3.500 кеше катнаша. Комсомолецлар, колхоз һәм мәктәп яшьләре бу традицион бәйрәмне зур түземсезлек белән көтеп алдылар.

Сарабиккул, Шөгер, Урдалы авылларында кросска әзерлек аеруча яхшы үтте. Сарабиккул тулы булмаган урта мәктәбенең комсомол оешмасы секретаре Фәрхетдинова, военрук Мостафин, колхоз комсомол оешмасы секретаре Мостафина иптәшләр кросска әзерлектә зур тырышлык күрсәтәләр. Биредә кросска 164 кеше катнаша. Алар инициативасы белән 3 тапкыр чаңгы походы оештырылды. Кроссның беренче көнендә үк монда ярышка 100 кеше чыкты.

Шөгер урта мәктәбендә комсомолецлардан кросска 350 кеше әзерләнде. Әзерлек чорында үткәрелгән чаңгы ярышларында 50 кеше ГТО һәм БГТО значокларына нормалар тапшырдылар.

Яңа Писмән районыннан киләчәк чаңгы эстафетасын каршылау өчен район үзәгендә йөзләрчә чаңгычылар чыга. Шул ук вакытта Беренче Май районына 5 кешедән торган эстафета чыгарыла. Алар колхозларда язгы чәчүгә әзерлекнең барышы, Кызыл Армия өчен бүләкләр җыюның барышы турында мәгълүматлар алып кайтачаклар.

М. ХӘМИДУЛЛИН.

РУЗВЕЛЬТ ЧЫГЫШЫНЫҢ АХЫРЫ

(Ахыры. Башы 3 нче биттә).

дә рәсми белдерү яки килешү төзү һич тә кирәк түгеллеген, бөек Англия джентельменының сүзенә Америка халкының ышануын һәм Азиядәге, Европадагы һәм Африкадагы варварлык көчләрен юк итәргә безнең тәмам риза икәнлегебез һәм тулысынча карар биргәнлегебез бөтенләй ачык икәнлекне белдердем. Икенче төрле итеп әйткәндә, Япониядәге дошманнарга карата безнең политикабыз нацист дошманнарга карата булган политика белән бер. Бу—барлык фронтларда нык көрәш алып бару һәм сугышны һичбер сүзсез капитуляция шартларында мөмкин кадәр тизрәк бетерү политикасы.

Бүген бөек һәм гади американың туган көне. Авраам Линкольн турындагы истәлекне безнең бөтен халкыбыз һәм безгә дус булган барлык Британия милләтләре, Советлар Союзы, Кытай халыклары һәм халык азатлыкны ярата торган һәм азатлык өчен үзенең тормышын бирәчәк һәрбер илдәге халык кадерле һәм саклый. 1862 нче елны президент Линкольн болай дигән иде: «Гражданнар, без тарихның хөкем карарыннан котыла алмыйбыз. Безне—конгрессны һәм хөкүмәтне —без үзебез нинди булуга карамастан искә алырлар. Безнең беребез дә, ул күренекле яки түбән урында торамы, барыбер моннан котыла алмас. Без үткәрә торган рәхимсез сынау безне актык буынга кадәр я мактаулы итәр яки хурлыкка калдырыр». Бүген Линкольнның бу сүзләрне әйтүенә 80 ел тула һәм бүген сугыш ялкыны Харьковтан алып Куньмингка кадәр, Урта диңгездән Коралл диңгезенә кадәр, Берлиннан Токиога кадәр бөтен кешелек дөньясын чолгап алды һәм без бу юлы да тарихның хөкем карарыннан котыла алмыйбыз. Без нык ышанабыз, алла ярдәме белән намус тантана итәр. Без ышанабыз, киләчәктәге буыннар XX нче гасыр уртасындагы яхшы ниятле кешеләрнең наданлык, ерткычлык, коллык һәм сугыш көчләрен юк итү максаты белән бергәләшеп эшләү һәм көрәшү өчен, берләшү өчен юл табулары чоры булганлыкны белерләр».

Җаваплы редактор **И. ҮЗБЕКОВ.**

Театрларда һәм киноларда

Татар дәүләт опера һәм балет театры. Бүген — *„Ильдар“*, 17 нче февральдә—*„Башмагым“*.

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Бүген спектакль булмый. 16 нчы февральгә алынган билетлар белән *„Ильдар“* спектаклен яки 19 нчы февральдә *„Хуҗа Насретдин“* спектаклен карарга мөмкин.

Зур драма театры. Бүген — *„Маскарад“*. 17 нче февральдә *„Фронт“*

Дәүләт циркы. Бүген—зур цирк тамашасы һәм французча көрәш ярышлары. Кич 8 сәгатьтә башлана.

„Электро“ — музыкаль комедия *„Антоша Рыбкин“*.

„Унион“—*„Котовский“*

„Пионер“—көндез һәм кич — *„Алтын кул“*.

„Чатки“—*„Өч мушкетер“*.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность-транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29. типография 36—60.

ПФ1028 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФ ИЯСЕ № Заказ 236